**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кремлевская ул., д. 9; Казань, 420111
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

Кремль урамы, 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111,
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының мәгариф идарәләре һәм бүлекләре җитәкчеләренә

Галимҗан Ибраһимов исемендәге
республика фәнни-гамәли
конференциясе үткәрү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013-2014 нче уку елы планы нигезендә Казан шәһәре мәгариф идарәсе белән берлектә, республика мәктәпләрендә әдәбият өлкәсендә сәләтле балаларны барлау, укучыларда фәнни эзләнү-тикшеренү күнекмәләре формалаштыру максатында, гомуми белем бирү оешмалары укучылары, укытучылары һәм студентлар өчен **2014 нче елның 19 нче апрелендә 10.00 сәгатьтә** Галимҗан Ибраһимов исемендәге VI республика фәнни-гамәли иҗади мирасын өйрәнү буенча конференциясе үткәрелә.

Үткәрү урыны: Казан шәһәре Мәскәү районы Г.Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясенең (адресы: 420039, Казан шәһәре, Восстание урамы, 48 нче йорт).

Конференциядә катнашучыларны теркәү: 9.00 дән 10.00 сәгатькә кадәр.

Укучыларга һәм озата килгән укытучыга командировка чыгымнары җирле бюджет исәбеннән түләнә. Конференциядә катнашучы укучының сәламәтлеге һәм иминлеге өчен җаваплылык озатучы педагогка йөкләнә.

Белешмәләр өчен телефоннар: 8(843) 564-31-51 (Казан шәһәре Мәскәү районы Г.Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясе); 8(843) 294-95-10 (Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы).

Нигезләмә теркәлә (кушымта): 2 биттә 1 экземплярда.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасының
мәгариф һәм фән министры Э.Н. Фәттахов

А.С. Шәрипова, 294-95-09



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

*Кушымта*

**Галимҗан Ибраһимов исемендәге VI республика фәнни-гамәли конференциясе нигезләмәсе**

**Конференциянең максатлары:**

- укучыларны, студентларны, укытучыларны Г. Ибраһимовның мәгърифәтчелек эшчәнлеге һәм иҗади мирасы белән таныштыру;
- фәнни эзләнүләрдә иҗадилыкка омтылыш тәрбияләү;
- сәләтле балаларны ачыклау, иҗади-интеллектуаль сәләтләрен активлаштыру һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру;
- укучыларда һәм студентларда милли гореф-гадәтләребезгә, рухи байлыгыбызга мәхәббәт тәрбияләү, социаль актив тормыш позициясе формалаштыру.

**Конференцияне оештыручылар:**

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты;
- Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе;
- Казан (Идел буе) федераль университеты;
- Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты;
- Казан шәһәре Мәскәү районының Г.Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясе.

**Конференциядә катнашучылар:**

Г. Ибраһимов исемендәге республика фәнни-гамәли конференциясе эшчәнлегендә гомуми белем бирү оешмалары укучылары, югары уку йорты студентлары, укытучылар катнаша.

**Конференцияне үткәрү шартлары һәм тәртибе:**

Конференция 2014 нче елның 19 нче апрелендә Казан шәһәре Мәскәү районының Г. Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясендә (адресы: 420039, Казан шәһәре, Восстание урамы, 48 нче йорт) үткәрелә.

Конференция кысаларында түбәндәге секцияләр эшли:

1. **«Татар әдәбиятында Г. Ибраһимов иҗатының эстетик һәм новаторлык үзенчәлеге».**

   Әлеге секция эшенең төп юнәлешләре:

   - язучы иҗатында табигать күренешләренең бирелеше;
   - Г. Ибраһимов иҗатында хатын-кыз язмышы проблемасы;
   - Г. Ибраһимов һәм балалар әдәбияты;
   - Г. Ибраһимов иҗатында музыка культы;
   - Г. Ибраһимов әсәрләрендә тел һәм стиль үзенчәлекләре;
   - Г. Ибраһимов әсәрләрендә җәмгыять һәм шәхес язмышы;
   - Г. Ибраһимовның тел гыйлеменә керткән өлеше һ.б.
2. **«Татар теле һәм әдәбиятының үсеш тенденцияләре: проблемалар һәм перспективалар».**
3. **Рус филологиясе секциясенең юнәлешләре:**
   - Г. Ибраһимов әсәрләрен чагыштырма аспектта тикшерү;

- рус әдәбияты үсешендә яңалыклар һәм проблемалар;
- рус теле белеме үсеше.

4. **Инглиз теле секциясенең юнәлешләре:**
   - Г. Ибраһимов әсәрләрен инглиз теленә тәрҗемә итү тәҗрибәсе;
   - Г. Ибраһимов әсәрләрен чагыштырма аспектта тикшерү.
5. **Тарих секциясенең юнәлешләре:**
   - Г. Ибраһимовның иҗтимагый эшчәнлеге;
   - Г. Ибраһимов әсәрләрендә татар халкының тарихы чагылышы.
6. **Иҗади эшләр секциясе: «Әдәби вә шигъри әсәрләргә һичбер төрле тәэсир бирмәгән адәм юк»**;
7. **Укытучылар секциясе: «Укыту-тәрбия процессында Г. Ибраһимов мирасын файдалану».**

Конференциядә катнашу өчен оештыру комитеты адресына 2014 нче елның 10 апреленә кадәр гариза (үрнәктәгечә), чыгышның басма һәм электрон формада тезисы *(1 бит басма текст , кырлар - 2 см, интервал – 1,5, шрифт – Times New Roman, 14)*, фәнни-тикшеренү эше җибәрелә. Фәнни-тикшеренү эшенең, кайсы секциягә җибәрелүенә карамастан, Г. Ибраһимовның әдәби иҗаты, киңкырлы эшчәнлеге белән бәйле булуы таләп ителә.

Катнашучыларның эшләре галимнәр тарафыннан 2014 елның 14 нчы апреленә кадәр тикшерелеп бәяләнә, һәр секциягә яклауга 15 эш тәкъдим ителә.

Уңай бәяләмә алган укучыларның исемлеге Казан шәһәре Мәскәү районының Г. Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясенең рәсим сайтында (https://edu.tatar.ru/moskow/page2285.htm/page2286.htm) урнаштырыла.

Чыгыш ясау өчен һәр катнашучыга 5 минут вакыт бирелә.

Белешмәләр өчен телефоннар: 8(843) 564-31-51, 8(843) 564-49-61 (Казан шәһәре Мәскәү районы Г. Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясе); 8(843) 294-95-10 (Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы).

E-mail: G17.kzn@edu.tatar.ru

**Г. Ибраһимов исемендәге**
**республика фәнни-гамәли конференциясендә катнашу өчен**
**заявка үрнәге**

| | |
|---|---|
| Чыгышның темасы | |
| Катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | |
| Эш яки уку урыны (мәктәп, сыйныф) | |
| Вазифасы | |
| Фәнни җитәкченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | |
| Фәнни җитәкченең эш урыны | |
| Вазифасы | |
| Элемтә өчен телефон, адрес | |
| Чыгыш өчен кирәкле техник чаралар | |
| Секция | |

Лист согласования к документу № 4771/14 от 31.03.2014
Инициатор согласования: Шарипова А.С. Начальник отдела национального образования
Согласование инициировано: 31.03.2014 12:43

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | - | Согласовано 31.03.2014 12:43 | - |
| 2 | Мустафин Д.М. | - | Согласовано 31.03.2014 14:02 | - |
| 3 | Фаттахов Э.Н. | - | Подписано 31.03.2014 18:49 | - |